

Бу районнын Красномайский авылында яшәvчеләрнен әлеге искиткеч кошны кvпкә кvбрәк кvрv момкинлеге бар икән, чонки тавис-павлин һәм анын ике дусты - Иван Степанович Жидкиннын ишегалдында яши.

Павлин хужасын матур койрыгын жәеп янгыр якынаюын хәбәр итә һәм котелмәгән тавыш белән таныш булмаган кешенен килvенә реакция ясап куркыныч турында кисәтә ала. Әмма анын тавышы безнен әтәчләрнен белән чыгыштырып булмый; әтәчләребез жырына конкурент тvгел. Бу могжизалы кошлар тавышын койрыгына баскан мәчеләр тавышы белән чагыштыралар.  - Павлин аерым карауны таләп итми, - ди Иван Степанович Жидкин. - Кышны әйбәт кичерәләр, ин моһиме - туклану балансланган булсын. Экзотик кошлар ризыкта бик таләпчән тvгел - ашлык һәм комбикорм белән туклана, витаминнарны бакчаны утаганнан сон калган vләннәрдән алалар.

Павлиннар гадәти сарайчикта яши, йо- рергә вольерга чыга. Хужасы алар очен барлык климат шартларын да тудыра, кирәк икән, хәтта жылыткычлар да куя - кош барыбер жылы ярата. Ә менә чит кешеләргә тvзми, хәтта чеметеп тә ала.

Павлиннарнын матурлыгы турында язу тvгел, кvреп белергә кирәк - чын салават кvпере! Иван Степанович әйтvенчә, елдан-ел кош арта бара - могжиза. Тик шунысы кызыклы: август азагына ук ул матур койрыгы белән аерылыша: июльнен икенче яртысында никах вакыты тәмамлана һәм искиткеч койрык vз актуальлеген югалта. Яна койрык анын кышын vсәчәк, ә май аенда ата тавис янә дусларына онытылмас тәэсир ясый.

Иван Степановичнын ишегалды зур, урыны һәркемгә дә житә. Экзотик кошлар белән бергә биредә экзотик токым тавыклары бар: шабо, китайская шелковая, колумбийская брама, павловская серебристая, карликовый кучерявый кохинхин, адлерская. Ә хужа кvгәрченнәрне дә ярата. Анын нинди генә токымнары юк: почтовые, иранские головатые, бакинские, славянские, артемоны, рябые, павлины, крестовые монахи, северокавказские. Барысы да бергә тату яшиләр.

- Хобби буларак асраган кошларны яраттым, – ди И.С.Жидкин. - Минем мавыгуым мәшәкатьле булса да, кvп игътибарны һәм хезмәтне таләп итсә дә, канатлыларым арасында мин кондәлек ыгы-зыгыдан ял итәм. Алар арасында булам да vземне яхшырак, тынычрак хис итәм.

**Н.ХӘЛИЛ**